**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.10.2022 № 1051

2022 елга һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 49, 51 маддәсе нигезендә “Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында” 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләмен һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм күрсәтелгән законга кушымтада бәян ителергә тиешле мөлкәт хакын билгеләү методикасы, шулай ук “Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр берлеге” коммерцияле булмаган партнерлык мәгълүматларына нигезләнеп, Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгене билгеләргә:
1.1. 2022 елга гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме:
1.1.1. ялгыз яшәүче граждан өчен - 902 638,00 сум;
1.1.2. Ике кешелек гаилә өчен - 1 148 812,00 сум;
1.1.3. Өч кешелек гаилә өчен - 1 477 044,00 сум;
1.1.4. Дүрт кешелек гаилә өчен - 1 969 392,00 сум;
1.1.5. 5 кешедән торган гаилә өчен - 2 461 740,00 сум;
1.1.6. Алты кешелек гаилә өчен - 2 954 088,00 сум;

1.1.7.җиде кешелек гаилә өчен - 3 446 436,00 сум;

1.2. 2022 елга гаиләнең һәр әгъзасына (ялгыз яшәүче гражданга) туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме:

1.2.1. ялгыз яшәүче гражданин өчен - 25 969,00 сум;

1.2.2. Ике кешелек гаилә өчен - 16 526,00 сум;

1.2.3. Өч кеше һәм аннан да күбрәк кеше өчен - 14 165,00 сум.

2. Әлеге карарның 1.2 пунктчасында күрсәтелгән керемнең максималь күләмен социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә куйганда файдаланырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.М.Заһидуллин